РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

22.11.2013

№ 128-п

Авыл җирлекләре, учреждение, оешма
һәм предприятиеләр арасында
Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап
"Бөек Җиңү яулап алганнарны
чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән
иҗат-отчет концертлары үткәрү
һәм күргәзмәләр оештыру турында

Районыбыз хезмәт ияләренең, аеруча яшьләрнең ялын файдалы итеп оештыру һәм хезмәт кешесенең рухи ихтыяҗын баету, халык талантларын үстерү, яшьләргә өлкәннәр тормышындагы уңай традицияләрне тапшыру максатыннан һәм шулай ук төрле яшьтәге кешеләрне авылның мәдәният тормышына якынайту, аларның активлыгын үстерү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. 2014 елның гыйнвар аеннан ноябрь аена кадәр районда авыл җирлекләре, учреждениеләр, оешма һәм предприятиеләр арасында "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертлары һәм күргәзмәләр оештырырга. 2015 елның апрель аенда Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан иң яхшы дип табылган концерт номерларыннан Гала концерт оештырырга.

2. "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат - отчет концертлары һәм күргәзмәләр оештыру комитеты составын расларга (теркәлә).

3. "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертларын үткәрү графигын расларга(теркәлә).

4. "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертлары һәм күргәзмәләре нигезләмәсен расларга (теркәлә).

5. "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән концертларда катнашучы коллективларның чыгышларын бәяләү өчен тәкъдим ителгән жюри составларын расларга (теркәлә).

6. Авыл җирлекләре башлыклары, мәдәният хезмәткәрләре, урыннардагы белгечләр тарафыннан иҗади ярдәм күрсәтүне оештырырга.

7. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Т.Г.Шәрәфиевка йөкләргә.

8. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ш.Ә.Сөнгатовка катнашкан коллективларны бүләкләү өчен финанс чыганакларын табуны тәкъдим итәргә.

9. Концертларны үткәрү урыны итеп Саба һәм Шәмәрдән мәдәният йортларын һәм авыл мәдәният йортларын билгеләргә. Бу мәдәният йортларының җитәкчеләренә (Р.Хаҗиева, А.Габделхаков) концертларны үткәрү өчен бөтен шартларны булдыруны тәкъдим итәргә.

10. Бу чараларның барышын "Саба таңнары" газетасында (Р.Г.Исмәгыйлов) һәм "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясе (Ә.Г.Мөбәрәкова) тапшыруларында даими яктыртып баруны оештырырга.

Саба муниципаль
районы башлыгы Р.Н.Минниханов

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013
№ 128-п карары белән расланды

Авыл җирлекләре һәм учреждение, оешма һәм предриятиеләр арасында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертлары үткәрү һәм күргәзмәләр оештыру буенча комитеты
СОСТАВЫ

1. Гасыймов Р.М. – Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе.
2. Шәрәфиев Т.Г. – Саба муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча 1 нче урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары.
3. Галимуллина Д.М. - район хатын–кызлар Советы рәисе (килешү буенча).
4. Гарипов И.Р. - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлеге начальнигы
5. Гафиятуллин Ә.Н. – ветераннар Советы рәисе (килешү буенча)
6. Закиров Ф.Ф. – ТР хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча).
7. Исмәгыйлов Р.Г. - " Саба таңнары" газетасы мөхәррире (килешү буенча)
8. Мөбәрәкова Ә.Г. - "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясе директоры (килешү буенча)
9. Хафизов М.Г. - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы.
10. Шакиров И.Ф. - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013
№ 128-п карары белән расланды

Авыл җирлекләре, учреждение,
оешма һәм предриятиеләр арасында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап
"Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән
иҗат -отчет концертларын, күргәзмәләрне бәяләү өчен
ЖЮРИ СОСТАВЫ

**Саба зонасы буенча**

1. Батырханова Г.Н. - Саба Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры (килешү буенча)

2. Габделхаков Г.Г. - район мәдәният йорты үзешчән сәнгать җитәкчесе (килешү буенча)

3. Галимуллина Д.М. - район хатын –кызлар Советы рәисе (килешү буенча).

4. Мөбәрәкова Ә.Г. - "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясе директоры (килешү буенча)

5 . Мусина З.С. - "Саба таңнары" газетасы журналисты (килешү буенча)

6. Хафизова Ч.Ф. - Саба балалар сәнгать мәктәбе директоры (килешү буенча).

7 . Хәнәфиева А.Ш. - Саба гимназиясе директоры (килешү буенча)

8 . Хәсәнов Р.М. - Саба шәһәр җирлеге башлыгы.

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013
№ 128-и карары белән расланды

Авыл җирлекләре, учреждение, оешма һәм предриятиеләр арасында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертларын, күргәзмәләрне бәяләү өчен
ЖЮРИ СОСТАВЫ

**Шәмәрдән зонасы буенча**

1. Аксанова Л.М. - балалар сәнгать мәктәбенең Шәмәрдән филиалы директоры (килешү буенча)
2. Гәрәев А.Н. - Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы
3. Зәйнетдинова Г.Н. – Шәмәрдән мәдәният йорты методисты (килешү буенча)
4. Хаҗиева Р.И. - Шәмәрдән мәдәният йорты директоры (килешү буенча)
5. Әсретдинова Р.С. - Шәмәрдән мәдәният йортының үзешчән сәнгать җитәкчесе (килешү буенча)

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013
№128-п карары белән расланды

Авыл җирлекләре, оешма, предприятиеләре һәм учреждениеләре арасында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда" дип исемләнгән иҗат-отчет концертлары һәм күргәзмәләр оештыру
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Районыбыз авыл җирлекләре, оешма, предприятиеләре һәм учреждениеләре арасында иҗат- отчет концертлары оештыруның максаты:

- районда сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- яшьләрнең һәм хезмәт ияләренең ялын файдалы итеп оештыру;
- халык талантларын үстерү, яшьләргә өлкәннәр тормышындагы уңай традицияләрне тапшыру, хезмәт кешесенең рухи ихтыяҗын баету;
- күргәзмәләр һәм альбомнар аша Бөек Ватан сугышының һәм районыбызның тарихын пропагандалау.

Иҗат-отчет концертларын үткәрү тәртибе һәм шартлары:

1. Концерт - программаларда бирелгән теманың чишелеше, жанрларның төрлелеге, номерларның образлы сәнгати чишелеше булуы шарт.

2. Иҗат-отчет концертларында авыл җирлегендә, оешма,предприятие һәм учреждениеләрдә эшләгән төрле профессия кешеләре катнаша ала.

3. Саба һәм Шәмәрдән мәдәният йортларының,авыл мәдәният йортларының фойеларында күргәзмәләр оештыру.

4. Тамашачыга тәкъдим ителә торган концерт программасының 2 сәгатьтән артмавы шарт.

Иҗат-отчет концерты сәнгатьнең түбәндәге төрләре буенча үткәрелә:

1. Пролог (Бөек Җиңүгә багышланган театраль күренеш.10-15 минут)
2. Музыка сәнгате
3. Җыр сәнгате
4. Бию сәнгате
5. Шигърият
6. Оригиналь жанр

Иҗади чыгышларны бәяләү тәртибе:

1. Пролог. Театраль күренеш - 15

2. Музыка сәнгате.
- курай -5
- тальян -5
- баян -10
- уен кораллары ансамбле - 20
- инструменталь ансамбль - 25

3. Җыр сәнгате:

- ялгыз башкаручы - 5
- дуэт, трио, квартет - 10
- вокаль ансамбль - 15
- гаилә ансамбле - 20
- фольклор коллектив - 30

4. Бию сәнгате:

- ялгыз башкаручы -5
- парлы бию -10
- күмәк бию - 20

5. Шигърият:

- ялгыз башкаручы - 5
- иҗади чыгыш -10

5. Оригиналь жанр:

- фокус -10
- жонглер -10
- клоунада - 10
- пантомима -10

6. Финал (5-10 минут) -15

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013
№ 128-ч карары белән расланды

Авыл җирлекләре, оешма, предприятиеләре һәм
учреждениеләре арасында "Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда"
дип исемләнгән иҗат-отчет концертларын оештыру графигы (килешү буенча)

| № | *Предприятиеләр исемлеге* | *Узачак көне* |
|---|---|---|
| 1. | Саба аграр көллияте | 17.01.2014 |
| 2 | Саба гимназиясе | 24.01.2014 |
| 3 | Саба муниципаль районы "Сәләтле балалар өчен аерым предметларны тирәнтен өйрәнелә торган урта гомуми белем мәктәп-интернаты" | 31.01.2014. |
| 4 | " Сабагаз"эксплуатация җитештерү идарәсе | 07.02.2014 |
| 5 | " Татавтодор" ААҖ Саба филиалы | 14.02.2014 |
| 6 | Сак бүлеге (отдел охраны), ГИБДД.<br>ТР хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге.<br>Татарстан Республикасындагы Федераль миграция идарәсенең Саба районындагы бүлекчәсе.<br>Прокуратура, Район суды. Суд приставлары хезмәте. Адвокатура. | 21.02.2014 |
| 7 | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 нчы районара инспекциясе | 28.02.2014 |
| 8 | Җаваплылыгы чикләнгән " Саба МТС" җәмгыяте,<br>Җаваплылыгы чикләнгән " Сабагрохим" җәмгыяте.<br>"Илфани", "Тулпар"<br>Җаваплылыгы чикләнгән " Сабинскагропромснаб" җәмгыяте.<br>Җаваплылыгы чикләнгән " Сабагро" җәмгыяте | 07.03.2014 |
| 9 | "Торак коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе" ААҖ | 14.03.2014 |
| 10 | РФ пенсия фонды идарәсенең ТР Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе,<br>Район кулланучылар җәмгыятенең берлеге идарәсе, | 21.03.2014 |
| 11 | ТР Саба муниципаль районы " Олимп" балалар- яшүсмерләр спорт мәктәбе, " Спорткомплекс" муниципаль учреждениесе, ТР Саба муниципаль районының " Саба йөзү басейны физкультура-сәламәтләндерү комплексы" муниципаль учреждениесе . | 28.03.2014 |
| 12 | Район почта элемтәсе идарәсе, Район электр элемтәсе узелы<br>Район электр челтәре (РЭС), Энергосбыт | 04.04.2014 |
| 13 | ТР Федераль казначылык идарәсенең Саба районы буенча бүлеге,<br>ТР финанс министрлыгының казначылык департаментының Саба районы территория бүлекчәсе,<br>Саба муниципаль район финанс – бюджет палатасы. | 11.04.2014 |
| 14 | Район Үзәк шифаханәсе .<br>31 нче номерлы Район үзәк аптекасы.<br>"Казанские аптеки". | 18.04.2014 |
| 15 | Җаваплылыгы чикләнгән "Рамазан" җәмгыяте<br>Җаваплылыгы чикләнгән "Яшен" җәмгыяте | 25.04.2014 |
| 16 | "Ак Барс" ачык акционерлык җәмгыятенең Казан филиалы Саба өстәмә офисы, Россия саклык банкы ачык акционерлык җәмгыятенең | 02.05.2014 |

| | | |
|---|---|---|
| | 4642 нче номерлы Саба бүлекчәсе<br>Татфондбанк, Россельхозбанк. | |
| 17 | Районның халыкны социаль яклау бүлеге, “Балкыш» социаль хезмәт күрсәтү үзәге, Шәмәрдәндәге реабилитация үзәге, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге. | 03.10.2014 |
| 18 | “ Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясе, «Саба таңнары” газетасы редакциясе<br>Россия эчке эшләр министрлыгының “ Саба” муниципальара бүлеге | 10.10.2014 |
| 19 | Җаваплылыгы чикләнгән “ Экопродукт” җәмгыяте, “Просто молоко”<br>Җаваплылыгы чикләнгән “ Саба тәрәзәләре” җәмгыяте | 17.10.2014 |
| 20 | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты.<br>Саба муниципаль районы Советы.<br>Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы.<br>Саба муниципаль районы авыл хуҗалыгы идарәсе. | 24.10.2014 |
| 21 | Саба үзәк китапханәсе,Балалар сәнгать мәктәбе,<br>Балалар иҗат үзәге,Район мәдәният йорты | 31.10.2014 |
| 22 | “ Росгосстрах” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасындагы филиалы шәһәр тибындагы Байлар Сабасы Агентлыгы.РСУ, Дом быта. | 07.11.2014 |
| 23 | Җаваплылыгы чикләнгән “ ПМК-159” җәмгыяте | 14.11.2014 |
| 24 | Саба муниципаль районы гражданнар саклау идарәсе.<br>Татарстан Республикасы ирекле янгынга каршы көрәш җәмгыятенең Саба районы филиалы.<br>Татарстан Республикасы буенча 129 нчы янгын сүндерү часте.<br>Татарстан Республикасы тирә эзләү –коткару хемәтенең<br>4 отряды (Шәмәрдән). | 21.11.2014 |
| 25 | Җаваплылыгы чикләнгән “ Автотранспорт” җәмгыяте.<br>“Бердәм тәрәзә” хезмәте | 28.11.2014 |
| 26 | Саба районы дәүләт ветеринария берләшмәсе<br>ТЦ Универмаг, ООО Герат”, ЧП “ Хасанов”, ЧП “ Мубаракзянов”, ООО “ Мир”, ЧП” Иванов”, ИП Хисанов Б.Х. , ООО “ФРГ”. | 5.12.2014 |
| | **ШӘМӘРДӘН ЗОНАСЫ БУЕНЧА.** | |
| 1 | Шәмәрдән лицее | 16.01.2014 |
| 2 | Югары Утар балалар йорты-интернаты | 23.01.2014 |
| 3 | Шәмәрдән участок шифаханәсе | 30.01.2014 |
| 4 | “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе “ ААҖ | 06.02.2014 |
| 5 | Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр линия производство идарәсе | 13.02.2014 |
| 6 | “Торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе” ААҖ | 20.02.2014 |
| 7 | Җаваплылыгы чикләнгән “ ТАТМИТАгро” җәмгыяте | 27.02.2014 |
| 8. | Татнефтепродукт” ААҖ “ Шәмәрдәннефтепродукт” филиалы | 06.03.2014 |
| 9. | “Яшьлек” яшьләр мәдәни- спорт үзәге | 13.03.2014 |
| 10. | Шәмәрдән тимер юл станциясе | 20.03.2014 |
| 11. | Җаваплылыгы чикләнгән “ ТАТагро” җәмгыяте | 27.03.2014 |
| 12. | Шәмәрдән мәдәният йорты,Аллаһияр һәм Хөснулла Валиуллиннар исемендәге Саба сәнгать мәктәбенең Шәмәрдән филиалы | 3.04.2014 |

Саба муниципаль район башлыгының
2013 елның 22.11.2013.
№ 128-п карары белән расланды

Авыл җирлекләре арасында “Бөек Җиңү яулап алганнарны чагылдырыйк әле җырларда” дип исемләнгән иҗат-отчет концертларын оештыру графигы (килешү буенча)

| № | Авыл җирлекләре | Үткәреләчәк көне | Үтәчәк урыны |
|---|---|---|---|
| 1. | Иштуган авыл җирлеге | 18.01.2014 | Лесхоз мәдәният йорты |
| 2. | Мишә авыл җирлеге | 19.01.2014 | Иштуган мәдәният йорты |
| 3. | Олы Нырты авыл җирлеге | 25.01.2014 | Ике Басу Арташ мәдәният йорты |
| 4. | Арташ авыл җирлеге | 26.01.2014 | Олы Нырты мәдәният йорты |
| 5. | Иске Икшермә авыл җирлеге | 1.02.2014 | К.Кибәче авыл клубы |
| 6. | Олы Кибәче авыл җирлеге | 2.02.2014 | Иске Икшермә мәдәният йорты |
| 7. | Түбән Шытсу авыл җирлеге | 08.02. 2014 | Сатыш мәдәният йорты |
| 8. | Сатыш авыл җирлеге | 09.02.2014 | Т.Шытсу мәдәният йорты |
| 9. | Эзмә авыл җирлеге | 15.02.2014 | Иске Мичән мәдәният йорты |
| 10 | Иске Мичән авыл җирлеге | 16.02.2014 | Эзмә мәдәният йорты |
| 11. | Явлаштау авыл җирлеге | 22.02.2014 | Шекше мәдәният йорты |
| 12. | Шекше авыл җирлеге | 23.02.2014 | Явлаштау мәдәният йорты |
| 13. | Кече Шыңар авыл җирлеге | 1.03.2014 | Тимершык мәдәният йорты |
| 14. | Тимершык авыл җирлеге | 2.03.2014 | К.Шыңар мәдәният йорты |
| 15. | Югары Симет авыл җирлеге | 8.03.2014 | Курсабаш мәдәният йорты |
| 16. | Курсабаш авыл җирлеге | 9.03.2014 | Югары Симет мәдәният йорты |
| 17. | Килдебәк авыл җирлеге | 15.03.2014 | Юлбат мәдәният йорты |
| 18. | Юлбат авыл җирлеге | 16.03.2014 | Килдебәк мәдәният йорты |